# ЯШЕЛ БИШЕК

ТР ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ РЕСУРСЛАР МИНИСТРЛЫГЫ БЕЛӘН ӘЗЕРЛӘНГӘН МАХСУС КУШЫМТА


## Ике айлык барышы

**Республикада 1 апрельдән 31 майга кадәр санитар-экологик хәлне яхшырту, яшелләндерү ике айлыгы игълан ителгән иде.**

Бу эшнең торышы белән таныштырып, экология һәм табигый ресурслар министры урынбасары Анатолий Щеповских түбәндәгеләрне хәбәр итте.

Әлеге ике айлык уңаеннан төзелгән комиссия егерме көн эчендә генә дә 1526 объектта тикшерү уздырган һәм табигать канунын бозуның 1350 очрагын теркәгән. Тикшерү барышында төзелгән 1200 беркетмәнең 140 ы юридик затларга карый, 560ы җитәкчеләрне, 500 е физик затларны административ җаваплылыкка тарту яки кимчелекләрне башка юл белән төзәттерүне максат итә. Рейдлар вакытында ачылган 665 рөхсәтсез чүп түгү урыннарының мәйданы 10 гектарга җитә. Бу көннәргә аларның нибары 275 ен генә (40 процент) яптыра алганнар. Табигатькә зыян китерүчеләргә шушы айлык барышында гына да 1,7 миллион сумлык штраф салынган. Әмма акча белән җәзалау үз нәтиҗәсен биреп бетерми. Рөхсәтсез рәвештә чүп түгү урыннарының елдан-ел артып торуы шуны күрсәтә.

Рөхсәт ителмәгән чүп базлары һәм тауларына битарафлыкта Түбән Кама, Яшел Үзән, Арча, Балтач районнары беренчелекне тота. Ә менә Саба, Теләче, Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск, Нурлат, Чирмешән, Алабуга, Менделеев, Чистай, Аксубай районнарында аларны бетерү өчен бөтен чаралар күрелгән.

Казан һәм аның әйләнә-тирәсендәге җирләрне шулай ук чиста дип әйтеп булмый. Рейдларда республика башкаласында экологиягә кагылышлы 337 тәртип бозу очрагы теркәлгән. Апрель аенда Казанда "чокып чыгарылган" 240 санкцияләнмәгән чүплекнең 20 проценты гына юк ителгән.

## Каенлыкның яңасы

**2007 елда булган давыл казанлылар яратып ял итә торган Каенлык әрәмәлеген пыран-заран китергән иде.**

Халык аны элеккегедән дә матуррак хәлдә күрергә тели. Агач утыртуга Урман хуҗалыгы, Яшьләр эшләре, туризм һәм спорт министрлыклары, шәһәр яны урман хуҗалыгы, Казан вузлары студентлары үз ихтыярлары белән чыга. Быел да андагы өмәдә 150 дән артыграк кеше катнашты.

Каенлыкны яңарту өчен шәһәр яны урман хуҗалыгы хезмәткәрләре быел 10 мең үсенте китерделәр. Алар арасында каен гына түгел, чыршы һәм нарат үсентеләре дә бар. Урман хуҗалыгы министрының беренче урынбасары Зиннур Хәйруллин сүзләренә караганда, узган ел утыртылган агачлар матур гына үсеп киткән.

– Озакламый биредә бер дигән парк булачак, – диде ул. 2013 ел универсиадасына кадәр алар ике метрлы "баһадир"ларга әйләнер.

– Безнең питомникта сиксән төрле декоратив агач үсентесе чәчеп үстерелә, – дип сөйләде, журналистларның кызыксынуына җавап итеп, шәһәр яны урман хуҗалыгы директоры Харис Мусин. – Безнең үсентеләрне, Татарстан шәһәрләреннән тыш, Россия калаларыннан, Үзбәкстан, Грузия һәм Казахстаннан да килеп алалар.

Урман хуҗалыгы министрлыгы белгечләре Казанны экологик таләпләргә җавап бирерлек яшел шәһәргә әйләндерү өчен агач утырту акциясен һәр яз һәм көздә дәвам итәргә, парклар өчен бүлеп бирелә торган җирләрнең мәйданнарын арттырырга кирәк, дип саныйлар.

# Әллә җитештерүчеләр битарафланды,
## әллә тикшерүчеләр шөбһәдә

ЙОМГАКЛАУ

**Беренче квартал йомгаклары буенча Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы үткәргән җыелыш менә шундый сорау куярга этәрде. Биредә чыгыш ясаучы министр Әгъләм Садретдиновның гына түгел, Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохиткә мониторинг ясау буенча Татарстан идарәсе башлыгы Сергей Захаровның да, Министрлар Кабинеты каршындагы Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе Булат Камаловның һәм башкаларның чыгышы да, нигездә, тәнкыйтькә корылган иде. Бу – безнең заман өчен күрелмәгән хәл.**

Экологиягә бәйле республика һәм федераль хезмәтләр, ниһаять, Татарстан Президенты һәм Премьер-министры тарафыннан әйләнә-тирә мохитне савыктыру турында әйтелә килгән сүзләргә формаль караудан котыла башлаганнармы? Әллә инде алар үз бурычларына бармак аша карауны һаман да дәвам итсәләр, үз вазыйфаларыннан колак кагасын төшенгәннәрме? Уйланган кешегә нәтиҗә ясарлык. Табигатьне моннан ары "көчләү" һәммәбезне һәлакәткә алып бара. Менә шуның өчен министрлык әйләнә-тирә мохитнең пычрануына өлеш кертүче һәр тармак буенча конкрет проектлар әзерләгән. Саный китсәң, күп алар: биологик калдыклар юк ителә торган биотермик чокырлар кору, нәҗес сыеклыкларны чистарту корылмаларының дөрес эшләвен тәэмин итү, җирле төзелеш материаллары – ком һәм гравий чыганакларын чамалап файдалану, транспортны евро-4 кә тәңгәл килә торган ягулыкка күчерү, көнкүреш һәм җитештерү калдыкларын чүплекләргә фәкать аралагач кына чыгару, сулыкларны пычранудан саклау... Әлеге юнәлешләрне савыктыруның төгәл чаралары ачыклаңган һәм боларны тормышка ашыру өчен җаваплы кешеләр билгеләп куелган. Алар белән җитәкчелек дилбегәсе министрның беренче урынбасары, республиканың баш инспекторы Марат Мәһдиевкә тапшырылу күңелдә өмет уята. Бәлкем, акча артыннан куып, табигатьне агулаучыларның койрыкларына авырттырыбрак баса башларлар. Менә үзегез генә уйлап карагыз: нибары өч ай эчендә үткәрелгән 900ләп инспектор тикшерүе вакытында әйләнә-тирә мохиткә зыян салырлык 898 очрак ачыкланган. Шуның буенча 394 юридик зат административ җаваплылыкка тартылган. Ә законны аеруча тупас бозучы 116 адәми затның эше прокуратурага тапшырылган.

Иманым камил, алар, чагыштырмача аз күләмдәге штраф белән котылып, элеккегечә үк пырдымсызлануларын дәвам итәчәк. Чөнки 898 закон бозучыга 1 миллион 495 сумлык штраф чәпәү – төкерек чәчрәтү генә бит ул. Табигатьне рәнҗетүнең һәр очрагы уртача нибары 1665 сумга төшә. Әле шуны да тулысынча түләтә алмыйлар. Министрлыкның Идел-Кама, Идел буе, Кама аръягы идарәләре үз карарларын азмы-күпме үтәтә алсалар, калган дүрт идарә, шул исәптән Кама буе, Көньяк-Көнчыгыш идарәләре һәм иң гаҗәбе – экологик иминлекне тәэмин итүче Дәүләт инспекциясе моңа һаман да бармак аша карый.

Балык башыннан чери дигән гыйбарә безнең көннәрдә тормышыбызның һәр өлкәсенә туры килеп тора. Кайбер территориаль идарәләрдә күзгә төтен җибәрүнең бик тә үзенчәлекле юлын сайлап алганнар. Исәп-хисап язмаларында закон бозуларны ачыклау күләмен күбрәк күрсәтеп, үзләрен эшлекләр рәтенә куймакчы булалар. Ә беркетмәләрен эзли башласаң, аларны әллә югалтканнар, әллә бөтенләй төзеп тормаганнар.

– Министрлыкка килә торган исәп-хисап язмаларының рәте-чираты юк, – диде бу уңайдан җыелышта Әгъләм Кыямович, мөмкин кадәр әдәп сакларга тырышып. Ләкин аның: "Әллә бу эш белән чит-ятлар мәшгульме?" – дип искәртүе кайберәүләргә үз кәнәфиләренең тазалыгын бүгеннән кайгырту кирәклеген сиздерә.

Дөрес анысы: экологиягә хезмәт итүчеләрнең эшен тавык чүпләп бетермәслек. Халыктан шикаять аеруча күп керүче "Вамин-Татарстан" ачык акционерлык җәмгыятенең районнардагы филиаллары, "Нәфис-косметик" ААҖнең предприятиеләре белән көрәшү, ай-һай, кыен. Халык аларның суны, һаваны пычратуыннан зарланып туймый, ә тикшерә башласаң, бармак янаучыларга очрыйсың. Ә бит тикшерүченең дә башы ике түгел. Менә шуннан килеп чыга инде ул төзелеп бетмәгән беркетмәләр.

Елдан-ел күбәеп, хәзер 900 мең берәмлеккә җиткән автомобильнең атмосферага газ чыгаруын киметү хакында күпме сөйлибез, күпме язабыз. Аңа карап, артыннан төтен дулатучы шакшы машиналар шәһәр эчендә дә, шәһәрдән читтә дә кимеми. Министр мең мәртәбә хаклы: аның бер сәбәбе тикшерү органнарында эшләүче кайберәүләрнең үз вазыйфаларына битараф каравы һәм хәтта намуссызлыгына бәйле. Моның шулай икәнен Сергей Захаров чыгышы тагын бер тапкыр раслады. Ул китергән саннардан чәчләр үрә торырлык. Соңгы вакытта Казан, Түбән Кама, Чаллы, Бөгелмә, Яшел Үзән кебек шәһәрләрнең һавасы борынга сизелерлек булып пычранган. Аларның кайсысында геоксид, кайсында формальдегид һәм аларның кушылмалары нормадан бер ярым, ике тапкырга югарырак күтәрелгән. Казанның Болак буенда авыр металлар һәм башка зарарлы матдәләрнең күләме мөмкин булганнан 27 тапкырга артыграк күзәтелгән көннәр бар икән. Әлмәттә дә һаваның узган ел белән чагыштырганда 1,5-3 тапкырга көчлерәк зарарлануын билгеләгән гидрометеорология һәм мониторинг идарәсе хезмәткәрләре.

Әлеге идарә экспертлары елга суларының элеккегедән ныграк пычрануы өчен дә борчыла. Көньяк-көнчыгышта ага торган Зәй, Минзәлә, Ык, Чирмешән һәм башка елгалардан алынган 1800 дән артык анализ нигезендә андагы суларга "бик пычрак" категориясен биргәннәр. Суын без эчә торган Куйбышев сусаклагычы да шундый ук бәягә лаек. Кама, Мишә, Иж, Зөя сулары шулай ук "пычрак"лар рәтендә. Сергей Захаров соңгы вакытта нефть төбәгендәге сулыкларда нефть катнашмаларының артуына аеруча басым ясады.


Булат Камаловның чыгышы да табигать өчен борчу өсти. Республикада кошкорт, терлек санының артуы, алардан чыккан нәҗеснең эшкәртелмәве экологик хәлгә начар тәэсир итә торган күренешләрнең берсенә әйләнгән. Шунысы шаккатмалы, хөкүмәт акча бирә торып та, Апас, Биектау, Питрәч, Теләче районнарында, Чаллы, Түбән Кама, Казан шәһәрләрендә Беккер чокырлары корылмаган. Шулай ук түләмә авырулы терлек күмелгән үләт базларының барсына да бетон саркофаг кидерә алмаганнар әле. Ә аларның саны республикада меңнән артып китә. Менә шулай чәйнәп биргәнне йота алмый торган халыкка әйләнәбез инде без. Берәүләребез белеп агулый, икенчеләребез белмичә агулана.

Бик борчылырлык тәэсир иткән әлеге җыелышның азмы-күпме ышаныч уята торган бер үзенчәлеге дә булды: кимчелекләребез күбрәк ачылу – битарафлыктан котылуның башы бит ул.

**Илсөяр ХӘЙРУЛЛИНА**



*Министр инспекторларның эшен тәнкыйтьләде...*



*... һәм Баш инспекторның вәкаләтләрен арттырды*



*Гидрометеорология һәм мониторинг идарәсе башлыгының (уртада) чыгышы залны пошаманга салды*

## Депутатлар бакчада

**Шәһәр бакчаларын һәм урамнарын тәртипкә китерүдән Дәүләт Советы депутатлары да читтә калмаска тырыша.**

Узган атнада депутатлар, парламент аппараты, "Бердәм Россия" партиясенең Татарстан бүлекчәсе башкарма комитеты хезмәткәрләре Лядской бакчасын тәртипкә китерделәр.

– Советлар Союзы заманыннан калган бу гадәт бүген дә яшәргә хаклы, – диде әлеге вакыйга уңаеннан журналистларга биргән интервьюсында Дәүләт Советы секретаре Лилия Маврина.

200 кешедән торган десант сәгать ярым эчендә бакчаны тазартып, аннан чүплеккә ике "КамАЗ" чүп-чар озатты.

## Кадерсезләү

Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының экологик иминлек дәүләт инспекциясе хезмәткәрләре санитар-эпидемиологик айлыкның беренче көннәрендә үк Казанда калдыкларны тиешенчә урнаштырмауның уннарча очрагына тап булдылар. Бу кара исемлеккә алар "Казтрансстрой" җәмгыятен, Вахитов районының вагон депосын, "Татмебель-Н" акционерлык җәмгыятен, "Татвтормет" ширкәтен, "Гидротехник корылмалардан файдалану идарәсе"н һәм шәхси эшмәкәр Шәрәпов ширкәтен теркәп куйдылар. Тикшерү нәтиҗәсендә физик затларга – биш, җитәкчеләргә – дүрт һәм юридик затларга бер беркетмә язылды. Төп гаепләү җитештерү барышында барлыкка килгән калдыкларны вакытында чүплекләргә озатмауга кагыла. Бер шикаять Россия табигать күзәтчелеге идарәсенең Татарстан бүлекчәсенә тапшырылды.

## Алманнар чүплек белән кызыксына



ХЕЗМӘТТӘШЛЕК

**Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында Германиянең ирекле Саксония дәүләте делегациясе вәкилләре белән очрашу булды.**

Сөйләшүләрне алманнар ягыннан Биомасса тикшерү буенча немец тикшеренү үзәгенең биогаз технологияләре бүлеге башлыгы доктор Франк Шольвин алып барды. Ә Татарстан ягыннан экология һәм табигый байлыклар министрының беренче урынбасары Марат Мәһдиев, министр урынбасары Анатолий Щеповских һәм башкалар катнашты. Сөйләшүнең төп темасы биоэнергетика һәм биотехнология мәсьәләләренә кагылды.

Марат Мәһдиевнең хәбәр итүенә караганда, алар Татарстанның чүпле полигоннарында, шул исәптән Самосырово каты калдыклар полигонында җыелган чүптән газ алу һәм аны файдалану хакында фикер алышканнар. Былтырның март-апрель айларында Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы Саксониядән килгән бер төркем галимнәр һәм инженерларны республика предприятиеләре белән таныштырган иде. Алар анда биогаз җайланмалары проектларын әзерләү өчен кирәкле материаллар җыю мөмкинлеген өйрәнделәр. Кызыксындырган объектлар белән таныштылар. Болар арасында Самосырово чүплегеннән тыш, Борындыктагы дуңгызчылык комплексы, "Кама Беконы" дуңгызчылык комплексы һәм Түбән Кама районындагы "Прикамская" мөгезле эре терлек фермасы бар. Предприятиеләрнең җитәкчеләре белән сөйләшүләр барышында алманлылар проект өчен мөһим бөтен мәгълүмат белән тәэмин ителделәр. Соңыннан Саксония вәкилләре Самосырово чүплегеннән газ җыю проектын тормышка ашыру өчен иң башта тикшеренүләр үткәрергә кирәклеген әйттеләр. Алманнарның биредәге газ запасларының күләмен һәм аннан алган электр энергиясенең үз кыйммәтен ачыкламыйча эшкә тотынмасы билгеле. Ләкин уртак проектларны тормышка ашыру өчен иң башта аны финанслау мәсьәләсен хәл итәргә кирәк.

# Буасы – ясалма, суы…чын,
## яки Каш ясыйм дип күз чыгару

Апрель башларындагы җылы көннәрнең берсендә Киров өлкәсенә барырга туры килде. Безнең белән чиктәш беренче авыллары Ностаны үтеп, бераз баруга, олы юлда су буе тезелгән машиналарны, ДАИларны күреп, йөрәк дерт итеп куйды: "Авария!" Баксаң, авария түгел, Дөреш исемле авылны су баскан икән. Без барганда инде су үз эшен эшләгән дә юлын алган, чокыр-чакырларда чыпчык тезеннән калган суны исәпкә алмаганда, урамда су юк иде диярлек. Тик биек дамба аша техникалар үтеп йөри алмаслык итеп ташыган су китергән һәлакәтнең нәтиҗәләрен күз алдына китереп була. Авыл кырындагы инеш буенда үскән агачлар су көченнән әле дә булса турая алмый утыра, капка төпләренә, бакча-каралтыларга килеп терәлгән ястык калынлыгындагы боз кисәкләре һәм болын буйлап алар бәреп җимергән сарайлар, Шушма елгасына кадәр аккан утыннар… Авылга мондый куәтле су кайдан килгән дип аптыраштык. Шушма елгасы ярларыннан тулып ташкан дияр идең, ул берничек тә тауга каршы күтәрелә алмый. Өстәвенә, Шушмада мондый калынлыктагы бозларның соңгы елларда булганы юк. Сораштыра торгач, белдек, авылдан өске якта эшләнеп бетмәгән һәм ныгытылмаган плотина булган икән. Шул яз көне "дулаган" да күрмәгәнне күрсәткән. Күрәсең, җаваплы иптәшләр, ясалма буада чын су һәм чын һәлакәт булмас дип ышанганнар.

Ә бит ясалма сулыклар һәм плотиналар һәркайда бар. Балтач районындагылардан да шундый куркыныч янамыймы икән? Аларның ныклыгы, төзеклеге, ахыр килеп, чисталыгы ни хәлдә? Әнә шуларны ачыкларга булдым.

"Районда 16 плотина бар. Шуларның тугызы федераль, җидесе республика балансында тора. Ясалма сулыкларның берсе дә авария хәлендә түгел", – ди "Мелиоратор" ширкәте җитәкчесе Хәниф Бариев. Ел саен аларның бер-икесенә ремонт ясала. Бүгенге көндә Нормабашта эш башланды, Түнтәрдә үткән ел тәмамланмаган иде. Шул эшне дәвам итәбез. Күпчелек плотиналарның төзеклеге өчен җирле үзидарә, кооператив җитәкчеләре җаваплы, федераль балансдагылары өчен Арча УЭОСы җавап бирә. Районның экологлары, санэпидстанция, МЧС хезмәткәрләре белән берлектә эшлибез.

Райондагы әлеге плотиналар нинди максаттан төзелгән булган соң? Баш мелиоратор әйтүенчә, алар ярдәмендә авыл хуҗалыгы карамагындагы җирләрне сугару күздә тотылган. Тик соңгы елларда бу эшкә игътибар кимегәч, хуҗалыклардагы сугару системаларының бик азы гына эшләп калган, төгәлрәге, эшкә яраклы хәлдә сакланган. Хәзер плотиналардан халык рәхәт күрә. Анда җәйләрен су коеналар, балык тоталар. Быел районда Сосна Пүчинкәсендә тагын бер шундый плотина – балык күле сафка басачак.

Плотиналар турында сүз чыккач, Хәниф Нәкыйповичтан соңгы елларда район үзәге халкы теленнән төшмәгән Көек плотинасы язмышы хакында да сорашмый кала алмадым. Моннан 15-20 еллап элек Балтач бистәсенең башта бер, аннан икенче урамында, хәзер инде бистәнең барлык аскы урамнарында яшәүчеләр грунт суларының җир өслегенә үтә якын булуыннан иза чигә башлады. Халык өчен ул чыннан да афәткә әйләнеп бара. Кайбер урамнарда өй астына су керүдән җәфа чиксәләр (әлеге су җәй уртасында гына юкка чыгып тора), икенче бер урыннарда су урамга ук "тибеп" чыкты. Кайчандыр гөлбакча үстергән кешеләрнең бакчалары сазлыкка әйләнде, капка баганалары, коймаларның тотнаклылыгы юкка чыкты. Алар кыегаеп бетте. Шулай ук каралты-кураларга да зыяны күп тиде. Балтачта яшәүче өлкән буын: "Мондый хәл элек юк иде, барысы да Көектә плотина төзелгәннән соң гына башланды", – дип ничә еллар чаң сукты. Шуннан соң, халык фикерен күздә тотып, әлеге плотинаның суы җибәрелде.

– Ләкин 470 кубометр су сыйдырышлы ул сулыктан котылу халыкны табигать салган җәбер-җәфадан азат итмәде, – дип сөйли Хәниф әфәнде. – Мин үзем дә аскы урамда яшим, өч ел буена су кимү турында уйлап та карамый.

Ул ел коры килсә, әлеге плотинаны кабат яңартырга туры килер дигән караштa тора. Ә менә бистәдә яшәүчеләрнең кайберләре, өй асларында, бакчаларда су кимәмәсә дә, җирнең ныклыгы артты дип саный. Бу – беренче өметле билге, тора-бара су юкка чыгачак, үз юлын табачак, дип ышана.

Бистә халкы махсус тикшеренүләр үткәреп, белгечләрнең нәтиҗәсен кулга алмыйча торып, плотинага яңа сулыш өргә каршы торачак. Хәер, җир өстенә ясалма сулык ясар алдыннан җир асты суларының торышын ачыклау кирәклеген мелиораторлар хәзер үзләре дә чамалыйдыр.

**Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА**